**Һәр җир карланган,**
**Сулар бозланган,**
**Уйный җил,буран,**
**Бу кайчак,туган?**



бәрешәләр-
шуалар-
ясыйлар-
уйныйлар-

бәрешәләр-бәрештеләр,бәрешкәннәр
шуалар-шудылар,шуганнар
ясыйлар-ясадылар,ясаганнар
уйныйлар-уйнадылар,уйнаганнар

# Үткән заман хикәя фигыль һәм аның мәгънәсе

Фигыль нәрсәне белдерә?

а)предметны

б)эш,хәрәкәт һәм хәлне

в)предметның билгесен

Фигыль нәрсә белән төрләнә?

а)заман

б)заман,зат-сан,барлык-юклык

в)заман,барлык-юклык

Фигыльнең барлык һәм юклык төре нинди кушымчалар ярдәмендә ясала?

а)-ма,-мә

б)-ган,-гән

в)-кан,-кән

Хикәя фигыль нинди мәгънә белдерә?

а)эшкә куша,боера,өнди

б)көтелгән эшнең киресен белдерә

в)эш,хәл,хәрәкәтнең булу-булмавын хикәяли,хәбәр итә

Билгесез үткән заман хикәя фигыль нинди кушымчалар ярдәмендә ясала?

а)-ды,-де;-ты-те

б)-ган,-гән;-кан,-кән

в)-ыр,-ер;-ар,-әр

Билгеле үткән заман хикәя фигыль нинди кушымчалар ярдәмендә ясала?

а)-ды,-де;-ты-те

б)-ган,-гән;-кан,-кән

в)-ыр,-ер;-ар,-әр

Хикәя фигыль ничә заманда килә?

а) бер

б) ике

в) өч

Фигыль җөмләдә күбрәк нинди җөмлә кисәге булып килә?

а) аергыч

б) хәбәр

в) тәмамлык

# Тест бәясе

“5”-хата юк

“4”-1-2 хата

“3”-3-5 хата

“2”-5-8 хата

Алтын көз китүгә,таягына таянып,ап-ак сакаллы кыш кунакка килде.Ул акрын гына җир өстенә күбәләк-күбәләк кар яудырырга кереште.Кар бөртекләре,җемелдәшеп,берсе белән уйнап,җир-анага коелдылар.Озаклامый җир өсте ап-ак юрган ябынды.Кыш үзенең ак келәмен җәйде.

җемелдәшеп-
юрган-
келәм-
кар бөртекләре-

җемелдәшеп-мерцая,сверкая
юрган-одеяло
келәм-ковёр
кар бөртекләре-снежинки

Синквейн – биш юлдан торган шигырь.

1 нче юл – төп сүз (исем)

2 нче юл – 2 сыйфат.

3 нче юл – 3 фигыль.

4 нче юл – җөмлә.

5 нче юл – нәтиҗә (1 сүз).

# Өй эше

1.126 нчы күнегү (мәкальләрне татарчага тәрҗемә итегез)
2.69 нчы бит (сорауларга җавап бирергә)
3.“Кышкы урман”темасына кечкенә күләмле хикәя язарга.